ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**« 30 » декабрь 2020 ел** **№ 1078**

**«2021-2023 елларга Арча муниципаль районы мәгарифен үстерү» муниципаль программасын раслау турында**

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Арча муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1."2021-2023 елларга Арча муниципаль районы мәгарифен үстерү» муниципаль программасын расларга.

2. Арча муниципаль районы башкарма комитетының 2017 елның 06 апрелендәге 360 номерлы «2017-2021 елларга Арча муниципаль районы мәгарифен үстерү» муниципаль программасын раслау турында (28.12.2017 № 1498; 18.10.2019 № 806 үзгәрешләр белән) карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының ФБП» МКУнә тәкъдим итәргә (С.П. Галимова):

3.1. Программаны финанслауны бу максатларга җирле бюджетта каралган ассигнованиеләр чикләрендә гамәлгә ашырырга.

3.2. Арча муниципаль районы бюджетын формалаштырганда чираттагы финанс елына муниципаль программа чараларын финанслау күләмнәрен җыелма бюджет бүленешенә кертергә.

4. Арча муниципаль районы башкарма комитетының «Мәгариф идарәсе» МУ (Р.Д.Мөхәммәдияров) муниципаль программа чараларын гамәлгә ашыруны координацияләүне тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны башкарма комитет җитәкчесе урынбасары А.Т.Мөхәммәтшинага йөкләргә.

Җитәкче Р.Р.Мөхәрәмов

# «2021-2023 елларга Арча муниципаль районында мәгарифне үстерү» муниципаль программасы

**«2021-2023 елларга Арча муниципаль районында мәгарифне үстерү» муниципаль программасы ПАСПОРТЫ**

| | |
|---|---|
| **Программаның исеме** | «2021-2023 елларга Арча муниципаль районында мәгарифне үстерү» муниципаль программасы (алга таба - Программа) |
| **Программаның заказчысы** | Арча муниципаль районы Башкарма комитеты |
| **Программаның максаты** | Арча муниципаль районы халкының үзгәрүчән ихтыяҗына һәм Арча муниципаль районы икътисады һәм җәмгыять үсеше перспективларына яраклаштырып, югары сыйфатлы белем белән тәэмин итү.<br>Арча муниципаль районы кешеләренең конкурентлыкка сәләтлелеген һәм яшәеш сыйфатын күтәрү өчен кирәкле шартлар буларак, муниципаль берәмлек үсешенең заманча механизмнарының тотрыклы системасын төзү.<br>«2014 - 2020 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасын, «Мәгариф» өстенлекле илкүләм проектын нәтиҗәле гамәлгә ашыру . |
| **Программаның төп бурычлары** | Халыкның һәкем тигез файдалана алуын тәэмин итә торган белем бирү челтәре һәм финанс-икътисадый механизмнар булдыру;<br>белем бирүнең сыйфатын күтәрү;<br>мәктәпкәчә белем бирүнең вариатив рәвешләрен үстерү;<br>белем бирү оешмаларының тәрбия-белем бирү процессында һәр баланың оптималь үсеш дәрәҗәсенә ирешү өчен мәгарифкә инновацион технологияләр кертү;<br>мәктәп укучылары өчен социаль адаптациянең бертигез башлангыч мөмкинлекләрен булдыру, актив һәм сәламәт яшәү рәвешенә ихтыяҗ тәрбияләү;<br>федераль дәүләт белем бирү стандартларын гомуми белем бирүнең 2 нче дәрәҗәсенә кертү;<br>гомуми белем бирү оешмаларын тәмамлаучыларның алга таба укуларына һәм югары технологияле икътисадта эшчәнлеккә әзерлеген тәэмин итү өчен белем бирү һәм белем бирү мохите эчтәлеген модернизацияләү;<br>Арча районы өстәмә белем бирү системасының мөмкинлекләрен киңәйтү, укуга югары мотивацияле яшь талантларны һәм балаларны үстерү өчен шартлар тудыру;<br>балалар өчен өстәмә белем бирүнең шәхси, психик һәм рухи тәрбияви системасын тотрыклы үстерү шартлары булдыру;<br>педагогик кадрлар составын һәм компетенцияләрен яңарту, педагогларны эшнең сыйфатын яхшыртуга һәм өзлексез һөнәри үсешкә мотивацияләү механизмнарын булдыру;<br>милли мәгарифне үстерү; |

<table>
<tr><td></td><td>сәләтле балалар белән эшләү системасының нәтиҗәлелеген арттыру;<br>Арча муниципаль районының милли һәм территориаль үзенчәлекләрен исәпкә алып, туган телдәге гомуми белем бирү оешмаларының оптималь челтәрен саклап калу;<br>хәзерге заман укытучысын педагогның һөнәри стандартын гамәлгә кертүгә әзерләү;<br>2017-2021 елларга Арча муниципаль районының социаль сәясәтендә инклюзия Концепциясен гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру;<br>мәгариф оешмаларында белем алу өчен махсус шартларны ФГОС һәм ФГОС ОВЗ таләпләренә туры китерү;<br>укучыларның һөнәри юнәлешенең бердәм системасын булдыру, алдан әзерлекне һәм профильле укытуны үстерү;<br>Россия укучылар хәрәкәтенең Татарстан төбәге бүлеген үстерү.</td></tr>
<tr><td>Программаны гамәлгә сроклары</td><td>2021 - 2023 еллар</td></tr>
<tr><td>Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары</td><td>2021-2023 елларга Программаны гамәлгә ашыру өчен кирәкле финанс чараларының гомуми күләме 2 468 566,0 мең сум тәшкил итә. Фараз характерында һәм билгеләнгән тәртиптә үзгәртелергә тиеш.<br>мең сум
<table>
<tr><td>Финанслау чыганагы</td><td>2021</td><td>2022</td><td>2023</td></tr>
<tr><td>Республика</td><td>714 960,6</td><td>739 730,7</td><td>722 777,9</td></tr>
<tr><td>Җирле бюджет</td><td>124 406,9</td><td>81 758,1</td><td>84 931,8</td></tr>
<tr><td>Бюджеттан тыш чыганаклар</td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>839 367,5</td><td>821 488,8</td><td>807 709,7</td></tr>
</table></td></tr>
<tr><td>Программаның максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашыруның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре һәм программаның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре (елларга бүленгән нәтиҗәләрне</td><td>Программа чараларын тулы күләмдә гамәлгә ашыру түбәндәгеләргә мөмкинлек бирә: өч яшьтән алып җиде яшькә кадәрге балаларга мәктәпкәчә белем бирүне 100 процент күләмендә тәэмин итү; мәктәпкәчә белем бирү оешмалары тәрбияләнүчеләренең гомуми саныннан мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында мәктәпкәчә белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандартына яраклаштырылган программалар буенча белем алучы тәрбияләнүчеләрнең чагыштырма авырлыгын 100 процентка җиткерү;<br>яңа федераль дәүләт белем бирү стандарты нигезендә белем алучы гомуми белем бирү оешмалары укучыларның чагыштырма авырлыгын 80 процентка кадәр арттыру; гомуми белем бирү оешмалары укытучыларының гомуми саныннан 30 яшькә кадәрге укытучылар санының чагыштырма күләмен 30 процентка кадәр җиткерү;</td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| **бәяләү индикаторлары)** | инвалид балаларның гомуми саннынан белем алуга каршылык булмаган, ерактан торып белем алу технологияләре буенча өйдә гомуми белем бирү программалары буенча белем алучы инвалид балаларның чагыштырма авырлыгын 100 процент дәрәҗәсендә саклау;<br>гомуми белем бирү программалары буенча укучыларның гомуми санынннан гомуми белем бирү программалары буенча укучыларның төрле дәрәҗәдәге олимпиадаларда һәм конкурсларда катнашучыларның чагыштырма авырлыгын 50 процентка кадәр арттыру;<br>БДИны 80 баллга һәм аннан да югарыракка тапшырган муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләрен тәмамлаучылар өлешен арттыру;<br>укучыларның профиль алды һәм профиль белеме белән колачлануын 100 процентка җиткерү;<br>хәзерге заман укытучысын педагогның һөнәри стандартын этаплап кертүгә 100 процентка кадәр әзерләү; |

**1. “2021-2023 елларга Арча муниципаль районында мәгарифне үстерү” муниципаль программасын (алга таба - Программа) гамәлгә ашыру өлкәсенә характеристика, шул исәптән төп проблемаларны тасвирлау**

Арча муниципаль районында мәгариф системасының заманча моделен формалаштыру өчен барлык шартлар да тудырыла: федераль, республика һәм район программалары гамәлгә ашырыла, гражданнарның гомуми белем алуга хокуклары дәүләт гарантияләре тәэмин ителә, инфраструктураны модернизацияләүгә, сәләтле балаларга ярдәм итүгә, укытучы потенциалын үстерүгә, яшь буынның сәламәтлеген саклауга зур игътибар бирелә. Мәгариф учреждениеләренең инновацион эшчәнлеге актив үсә.

Белем бирүнең һәркем файдалана алырлык булуы һәм сыйфаты халыкның тормыш дәрәҗәсен, кеше капиталының сыйфатын, халыкның социаль һәм хезмәт мобильлеген, яшәү урынын сайлаганда территориянең җәлеп итүчәнлеген билгели торган төп факторлар булып тора.

Белем бирүнең миссиясе - һәр гражданның уңай социаль, мәдәни, икътисадый потенциалын гамәлгә ашыру һәм ахыр чиктә - гражданның тулысынча социаль-икътисадый үсүе. Моның өчен белем бирү өлкәсе һәр кешенең һәрвакыт сыйфатлы белем бирү хезмәтләреннән файдалану мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш.

Муниципаль программаны гамәлгә ашыру түбәндәге өстенлекле юнәлешләр буенча башкарылачак: укучыларны социаль практикага җәлеп итү һәм аларга үзүсешнең потенциаль мөмкинлекләре турында мәгълүмат бирү, укучыларның фәнни, иҗади һәм эшкуарлык активлыгына ярдәм итү; лидерлык күнекмәләренә, инициативалы һәм талантлы яшьләргә ярдәмнең бербөтен системасын формалаштыру; укучыларга гражданлык белеме бирү һәм

патриотик тәрбия бирү, балалар һәм яшьләр арасында хокукый, мәдәни кыйммәтләрне формалаштыруга ярдәм итү.

Белем алу һәркем өчен мөмкин булу мәсьәләсе бүген шактый дәрәҗәдә хәл ителгән.

Төрле дәрәҗәдә белем бирүнең сыйфатын күтәрү системалы өстенлекнең икенчесе. Шул ук вакытта сүз белем бирү сыйфатын элек кулланылган критерийлар буенча күтәрү турында гына бармый, белем бирү нәтиҗәләренең халык ихтыяҗларына туры килүен тәэмин итү турында да, шулай ук җәмгыять һәм икътисад үсешенең перспектив бурычлары турында да бара. Сүз хосусый белем бирү нәтиҗәләре турында гына түгел, ә белем бирү системасы формалаштыра торган бөтен буынның сыйфатлы белем алу нәтиҗәсенә ирешү өчен мөмкинлекләр тигезлеге турында бара. Әлеге өстенлек контекстында барлык дәрәҗәләрдә дә "сыйфатлы" белем бирү турындагы күзаллауларны яңадан карау мәсьәләсе көн кадагында, шәхси үзләштерелгән һәм коллектив бүленгән белемнәрнең, компетенцияләрнең районда белем алу, шәхси уңышка ирешү өчен нигез булуын билгеләү. Гадәти белем бирү институтлары - балалар бакчалары, мәктәпләр мәгариф системасының үзәк элементлары булып калып, бүген балаларга өстәмә белем бирүнең даими үсә торган секторлары, үзлегеңнән белем алуның заманча чаралары белән тулыландырыла.

Заманча сыйфатка һәм сыгылмалылыкка бары тик кызыксынучы затларның, укучыларның үзләрен дә кертеп, аларның гаиләләренең актив катнашында гына ирешергә мөмкин. Шуңа күрә мәгариф өлкәсен күбрәк ачык булу юнәлешендә модернизацияләү, инициатива һәм активлык күрсәтү өчен белем алучыларның, аларның гаиләләрен һәм җирле берләшмәләрне дә кертеп, белем бирү процессына, белем бирү эшчәнлегенә турыдан-туры җәлеп итү аша зур мөмкинлекләр тудыру өстенлекле юнәлеш булып тора. Бу өстенлек ачык җәмгыять төзү бурычын гына түгел, хәзергә кадәр нәтиҗәле файдаланылмаган гаиләләр һәм оешмаларның киң белем потенциалын да чагылдыра.

Муниципаль программаның стратегик максаты - укучыларның уңышлы социальләшүе һәм үзләрен нәтиҗәле гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру, аларның мөмкинлекләрен үстерү һәм, җәмгыятьне инновацион- социаль юнәлештә үстерү мәнфәгатьләрендә, аннан файдалану.

Хәзерге вакытта Арча муниципаль районында мәгариф системасының тотрыклы эшләве тәэмин ителгән һәм аның киләчәк үсеше өчен алшартлар тудырылган.

2020 елның 1 сентябренә район муниципаль белем бирү челтәре 36 гомуми белем бирү оешмасын үз эченә ала: 15 урта мәктәп, 18 төп, 1 башлангыч мәктәп; шулардан 29 мәктәп (82 %) авыл җирлегендә урнашкан. 51 мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе, 2 башлангыч мәктәп-балалар бакчасы, 5 өстәмә белем бирү учреждениесе, шуларның МП -2, ХЭН -1, ДЮСШ -2 бар.

Арча муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү өлкәсендә белем бирү сәясәтенең мөһим өстенлеге булып белем алу мөмкинлеген һәм сыйфатын тәэмин итү буенча комплекслы чаралар тора.

Арча муниципаль районында 51 мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе эшли, шуларның 10сы - Арча шәһәрендә, аларда 2471 бала тәрбияләнә.

Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары челтәре яңа балалар бакчалары ачу нәтиҗәсендә киңәйде. Соңгы елларда 3 яңа мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе ачылды: 2018 елда -140 урынлы Арча шәһәренең “Сандугач” 6 нчы гомуми үстерү төрендәге балалар бакчасы", 2020 елда - 140 урынлы “Арча шәһәренең “Балачак” 7 нче гомуми үстерү төрендәге балалар бакчасы”, 2020 елда - 40 урынлы “Наласа балалар бакчасы”, капиталь ремонт үткәрү хисабына “Түбән Аты төп гомуми белем бирү мәктәбе” - “Урта Сәрдә башлангыч белем бирү мәктәбе- балалар бакчасы” филиалында мәктәпкәчә белем бирү төркеме ачылды.

Урыннар шактый артуга карамастан, районда вәзгыять кискен булып кала бирә. 2020 елның 1 сентябренә «Электрон балалар бакчасы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасында 1025 бала теркәлгән, аларның 116 сы-3 яшьтән зуррак, алар, урын булмау сәбәпле, мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләренә урнаштырылмаган.

Мәктәпкәчә белем бирү стандартын уңышлы тормышка ашыру өчен республика база мәйданчыгы булып 2 нче Арча балалар бакчасы билгеләнде. Әлеге учреждение базасында район балалар бакчалары тәрбиячеләре өчен семинарлар, осталык класслары, теоретик укыту семинарлары уздырыла;

-Татарстан Республикасының ике дәүләт теленә өйрәтү буенча заманча инновацион укыту-методик комплектларны сынау буенча республика сынауь мәйданчыгы (Арчаның 8 нче балалар бакчасы, 5нче балалар бакчасы);

-Арчаның 4 нче балалар бакчасы - баланы үстерү үзәге - «Төрле төстәге планета» программасы буенча сынау мәйданчыгы.

Бүгенге көндә Арча муниципаль районы гомуми белем бирү системасы бер яктан ирешелгән уңышлар, икенче яктан кайбер проблемалар булу белән характерлана.

Районда укучыларны профильле уку планнары нигезендә булачак һөнәри эшчәнлеккә максатчан әзерлек алып барыла. Иң ихтыяҗ зур профильләр: социаль - икътисадый, физик-математик, социаль - гуманитар, филологик, мәгълүмати-технологик профильләр.

Сәламәтлек буенча мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен белем бирү хезмәтләреннән файдалану проблемасын хәл итү өчен (алга таба - ОВЗ) өйдә дистанцион технологияләр кулланып укыту системасын үстерү проекты гамәлгә ашырыла.

«Мәгариф» өстенлекле илкүләм проекты бурычларын хәл итү барышында инновация һәм тәҗрибә-сынау эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге, мәгариф учреждениеләрен җиһазландыру дәрәҗәсе күтәрелде, инновацион программалар һәм проектларны гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләренә һәм укытучыларга грант ярдәме тәэмин ителде, белем бирү эчтәлеген яңарту процессы тизләтелде, мәгълүмати-коммуникация технологияләрен кертү активлашты, сыйныф җитәкчеләренә ярдәм итү системасы булдырылды. Белем бирү сыйфаты белән нәтиҗәләр буенча идарә итү өчен мониторинг системасы төзелә.

"Мәгариф" илкүләм проекты кысаларында:

- Лесхоз, Иске Чүриле, Яңа Кенәр урта мәктәпләре, Арчаның 7 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе һәм Арчаның 6 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе "Заманча мәктәп" федераль проекты старт алды. Проект мәгариф оешмаларының матди-техник базасын ныгытуга, гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыру шартларын камилләштерүгә юнәлтелгән.

- «Цифрлы белем бирү мохите» федераль проектына аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтүче В.Ф.Ежков исемендәге 1 нче Арча урта гомуми белем бирү мәктәбе кертелгән. Проект белем бирү процессларында катнашучыларның барысы да кертелгән яңа типтагы белем бирү мохитен төзүгә, заманча мәгълүмати-коммуникация җиһазлары белән тәэмин итүгә юнәлдерелгән. Әлеге мәктәпнең педагогик хезмәткәрләренең цифрлы технологияләр буенча квалификациясен күтәрү уздырыла.

- Арчаның 6 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе Татарстан Республикасында балалар-яшүсмерләр геологик хәрәкәтенең республика база мәйданчыгы булып тора. Укучылар туган якның гидрологиясен, файдалы казылмаларны һәм табигый байлыкларны өйрәнү буенча фәнни-тикшеренү эше белән шөгыльләнә, республика чараларында катнаша. Мәктәп КФУның нефть технологияләре институты белән хезмәттәшлек итә.

- Арчаның В.Ф.Ежков исемендәге аерым предметларны тирәнтен өйрәнү буенча 1 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе сәламәтлек саклау һәм сәламәтлекне яхшырту технологияләре тәҗрибәсен тарату буенча республика сынау- тәҗрибә туплау мәйданчыгы булып тора;

- Арчаның 5 нче гимназиясе, Арчаның 2 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе инклюзив белем бирүне гамәлгә ашыру буенча база мәйданчыклары;

- Арчаның 5нче гимназиясе, Ашытбаш урта гомуми белем бирү мәктәбе - милли мәгарифне гамәлгә ашыру буенча база мәйданчыклары.

Районда милли мәгариф үсешенең мөһим индикаторларының берсе - балаларга туган телдә белем бирүне оештыру һәм мәктәпләрдә туган телне өйрәнү күрсәткече.

Районда милли гомуми белем бирү учреждениеләре челтәре сакланган, ул татар телендә белем бирүче 27 мәктәпне үз эченә ала (2706 укучы). Татар балаларын туган телдә укыту район буенча 52,24% тәшкил итә. Дәүләт телләрен өйрәнү белән беррәттән, этно-мәдәни компонентлы Шурабаш төп гомуми белем бирү мәктәбендә башлангыч сыйныфларда15 мари баласы туган (мари) телендә белем ала, 15 мари (100%) туган телне предмет буларак өйрәнә.

Татар теле һәм әдәбияты укыту районның барлык мәктәпләрендә тормышка ашырыла, 100% укучы татар телен өйрәнә. Г.Тукай иҗатына багышланган "Мөлаем Шүрәле" республика конкурсы, Республика Тукай укулары, "Әдәби җәүһәрләр" Бөтенроссия конкурсы, Г.Тукай иҗаты буенча интеллектуаль конкурслар һәм башкалар үткәрелә. Татар теле укытучылары Мари Иле, Төмән һәм Пермь өлкәсе хезмәттәшләре белән актив хезмәттәшлек итә, үзара хезмәттәшлек турында килешүләр төзелде. Пермь, Төмән өлкәсе делегацияләре районыбыз мәктәпләренә киләләр, шулай ук Пермь өлкәсенә баручы делегация составында безнең район мәктәпләре вәкилләре дә бар иде.

Балаларга өстәмә белем алу мөмкинлеге районның 5 өстәмә белем бирү оешмасында тәэмин ителә. Укучылар сарае базасында фәнни-техник иҗат юнәлешләре буенча республика база мәйданчыгы булдырылды: авиамодельләштерү, суднолар модельләштерү, автомодельләштерү, роботлар төзү, картинг, агач төзелеш сәнгате. Өстәмә белем алу белән колачлау 93% тәшкил итә.

Мәгариф системасының барлык якларын һәм баскычларын үстерү стратегиясе мәгариф өлкәсендә федераль һәм республика программалары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Мәктәпкәчә белем бирүнең, башлангыч гомуми белем бирүнең, төп гомуми белем, урта гомуми белем, өстәмә белем бирүнең сыйфаты.

Мәктәпкәчә белем бирүнең сыйфаты:

- мәктәпкәчә белем бирү эчтәлеге,

-чыгарылыш сыйныф укучыларын әзерләүгә таләпләр (белем бирү эшчәнлеге нәтиҗәләре),

-предмет киңлеге мохите булдыру белән билгеләнә.

Арча муниципаль районында балаларның иҗади сәләтләрен алдан ук күрә белүне тәэмин итү, мәгълүматны тәнкыйди кабул итү күнекмәләрен үстерү, стандарт булмаган карарлар кабул итү, креативлыкка, уйлап табучанлыкка, командада эшләргә һәм мәктәпкә керүгә әзерләү өчен өстәмә белем бирү челтәре киңәйтелгән.

Соңгы елларда районда гомуми белем бирү оешмалары челтәре модернизацияләнде. Программада азкомплектлы гомуми белем бирү оешмаларын үзгәртеп кору һәм аларны база мәктәпләренә кушу юлы белән гомуми белем бирү оешмаларының оптималь челтәрен төзү буенча чаралар үткәрү каралган.

Арча муниципаль районы шартларында билгеләнгән проблемалар контекстында белем бирү системасын үстерү фаразын гамәлгә ашыру түбәндәге бурычларны үтәүне күздә тота:

-районда гамәлгә ашырыла торган белем бирү сыйфатын бәяләүнең республика бәяләү системасына туры килә торган механизмнарын булдыру;

-районда гомуми белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандарты (алга таба - ФГОС) таләпләре нигезендә төп белем бирү программаларын үзләштерүнең сыйфатын мониторинглау системасын булдыру;

-белем бирүнең сыйфаты һәм мәгариф оешмалары эшенең нәтиҗәләре турында мәгълүматның мөмкин кадәр ачык һәм һәркем файдалана алырлык булуын тәэмин итү;

- белем бирү сыйфатын бәяләүдә тышкы дәүләт- иҗтимагый ролен көчәйтү һәм эчке һәм тышкы бәяләүнең үзара оптимальлегенә ирешү;

-кулланучыларның белем бирү хезмәтләрен сайлый алу, белем бирүнең эчтәлегенә һәм технологияләренә төзәтмәләр кертүне тәэмин итә торган хосусый белем казанышлары турында мәгълүмат җыю һәм анализлау системасын булдыру.

**Мәгариф системасы кадрлары**

Арча районы мәгариф системасында 1997 кеше эшли, шуларның 1123 е - педагогик хезмәткәрләр. Укытучыларга карата ярдәмче персонал өлеше 43% тәшкил итә. Район мәктәпләрендә 35 яшькә кадәрге 140 педагог эшли.

"Мәгарифтә казанышлары өчен" күкрәк билгеле - 158 педагог; "РФ гомуми белем бирүнең мактаулы хезмәткәре" күкрәк билгеле - 116 педагог; ТРның атказанган укытучысы - 10 педагог; Мәгариф һәм фән министрлыгының Мактау грамотасы белән бүләкләнгән - 116 педагог; ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Мактау грамотасы белән бүләкләнгән - 197 педагог бар.

Республика грант хәрәкәтендә катнашу район укытучыларының дәрәҗәсен күтәрүгә, һөнәри-шәхси казанышларга дәүләт-иҗтимагый экспертиза нәтиҗәләре буенча матди кызыксындыру нигезендә аларның уңышлы һөнәри эшчәнлеген активлаштыруга юнәлтелгән.

01.09.2020 елга Арча муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында "Безнең яңа укытучы" грантын 6 кеше алды.

**Каршылыкларны һәм алар белән идарә итү чараларын анализлау**

Программаны гамәлгә ашыруның төп каршылыклары:

финанс-икътисадый: Программа чараларын финанслап җиткермәү,

норматив хокукый: Программа чараларына йогынты ясый торган кирәкле норматив актларны кабул итмәү яисә үз вакытында кабул итмәү;

оештыру һәм идарә итү: Программа кысаларында хәл ителә торган мәсьәләләрне җитәрлек дәрәҗәдә эшкәртмәү, идарә потенциалын җитәрлек дәрәҗәдә әзерләмәү, Программаны гамәлгә ашыруны мониторинглау системасының дөрес булмавы, чараларны гамәлгә ашыру срокларыннан артта калу;

Финанс-икътисадый каршылыклар Программа максатларына ирешү эшчәнлеген финанслашу күздә тотылган кайбер чараларны финанслап җиткермәү.

Норматив каршылыклар.

Каршылыкларны бетерү (киметү) Программаны гамәлгә ашыруны планлаштыруның сыйфатына, аны гамәлгә ашыруны мониторинглауны тәэмин итүгә һәм кирәкле үзгәрешләрне тиз арада кертүгә бәйле.

Оештыру һәм идарә итү каршылыклары.

Ялгыш оештыру схемасы һәм начар идарә итү потенциалы (шул исәптән яңа инструментлар белән эшләр өчен квалификациянең җитәрлек дәрәҗәдә булмавы) Программаны гамәлгә ашыру процессы белән нәтиҗәле идарә итүгә, Программада төп башкаручы һәм катнашучылар гамәлләренең килештерелмәвенә, мәгариф оешмалары дәрәҗәсендә программа чараларын гамәлгә ашыруның түбән сыйфатына китерергә мөмкин. Программаны даими һәм оператив мониторингны (шул исәптән социологик) гамәлгә ашыру нигезендә Программага төзәтмәләр кертү хисабына каршылыкны бетерү мөмкин.

**2. Программаның төп максатлары, бурычлары һәм чаралары, соңгы нәтиҗәләрне, аны гамәлгә ашыру срокларын һәм этапларын тасвирлау**

Программаның максаты: Арча муниципаль районы халкының үзгәрүчән таләпләре һәм Арча муниципаль районы икътисады үсешенең перспектив бурычлары нигезендә Арча муниципаль районында белем бирүнең сыйфатын югары дәрәҗәдә тәэмин итү; Арча муниципаль районы халкының конкурентлыкка сәләтлелеген һәм тормыш сыйфатын күтәрүнең кирәкле шартлары буларак, муниципаль берәмлекнең тотрыклы үсешенең заманча механизмнарын төзү; «Мәгариф» өстенлекле илкүләм проектын, «2014 - 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасын уңышлы гамәлгә ашыру.

Куелган максатка ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итү күздә тотыла:

- белем бирү челтәрен булдыру һәм халыкның гомуми белем бирү хезмәтләрен алуга тигез мөмкинлеген тәэмин итә торган икътисадый механизмнар булдыру;
- белем бирүнең сыйфатын күтәрү;
- мәктәпкәчә белем бирүнең вариатив рәвешләрен үстерү;
- һәр бала үсешенең оптималь дәрәҗәсенә ирешү өчен мәгариф оешмаларының тәрбия-белем бирү процессына инновацион белем бирү технологияләре кертү;
- мәктәптә уку өчен тигез башлангыч шартлар тудыру;
- гомуми белем бирү оешмаларын тәмамлаучыларның алга таба укуга һәм югары технологияле икътисадта эшчәнлеккә әзерлеген тәэмин итү өчен, белем бирү һәм мәгариф мохитенең эчтәлеген модернизацияләү;
- балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләре эшчәнлеге эчтәлеген яңарту һәм өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатын арттыру;
- педагогик кадрлар составын һәм компетенцияләрен яңарту, педагогларны эшнең сыйфатын яхшыртуга һәм өзлексез һөнәри үсешкә мотивацияләү механизмнарын булдыру;
- милли мәгарифне һәм тәрбияне үстерү;
- Арча муниципаль районының милли һәм территориаль үзенчәлекләрен исәпкә алып, туган телдәге гомуми белем бирү оешмаларының оптималь челтәрен саклап калу;
- сәләтле балалар белән эшләү системасының нәтиҗәлелеген арттыру;
- хәзерге заман укытучысын педагогның һөнәри стандартын этаплап кертүгә әзерләү;
- 2015-2018 елларга Арча муниципаль районының социаль сәясәтендә инклюзия Концепциясен гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру;
- мәгариф оешмаларында белем алуның махсус шартларын ФГОС һәм ФГОС ОВЗ таләпләренә туры китерү;
- укучыларның һөнәри юнәлешләренең бердәм системасын булдыру, алдан профильле әзерләүне һәм профильле укытуны үстерү;
- Россия мәктәп укучылары хәрәкәтенең Татарстан төбәк бүлекчәсен үстерү.

Төп чаралар кысаларында традицион чаралар уздыру һәм укучыларның иҗади, фәнни, спорт эшчәнлеген үстерүгә юнәлтелгән яңа муниципаль, төбәк һәм республика чараларын формалаштыру каралган.

Белем бирүнең югары сыйфатын тәэмин итү оештыру, кадрлар, инфраструктура, матди-техник һәм укыту-методик шартлар тудыруга гына бәйле түгел. Белем бирү хезмәтләренең тотрыклы югары сыйфатын тәэмин итүнең һәм аны арттыруның мөһим өлеше булып объектив һәм белем бирүнең барлык дәрәҗәләрен үз эченә алган сыйфатны бәяләү системасы тора.

Программаны гамәлгә ашыру срогы - 2021-2023 еллар.

**3.Программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү**

2021-2023 елларга Программаны гамәлгә ашыру өчен кирәкле финанс чараларының гомуми күләме - 2 468 566,0 мең сум. Фараз характерында һәм билгеләнгән тәртиптә үзгәрергә тиеш.

*мең сум*

| Финанслау чыганагы | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел |
|---|---|---|---|
| **Республика бюджеты** | 714 960,6 | 739 730,7 | 722 777,9 |
| **Жирле бюджет** | 124 406,9 | 81 758,1 | 84931,8 |
| **Бюджеттан тыш** | | | |
| **Барлыгы** | 839 367,5 | 821 488,8 | 807 709,7 |

Программаны гамәлгә ашыру максатларында төрле дәрәҗәдәге бюджетлар ресурслары файдаланылачак. Программаны финанслау механизмы дәүләт ярдәменең төрле рәвешләрен куллануны күздә тота, шул исәптән:

а) чараларны турыдан-туры республика бюджетларыннан финанслау;

б) субсидияләр һәм субвенцияләр бирү.

**4. Программаны гамәлгә ашыру механизмы**

Программаны гамәлгә ашыру өчен җаваплылык «Арча муниципаль районы Башкарма комитетының "Мәгариф идарәсе» муниципаль учреждениесенә йөкләнә, ул максатчан индикаторларны мониторинглауны гамәлгә ашыра. Әлеге Программаны үзгәртү аны гамәлгә ашыру барышын ел саен анализлау нәтиҗәләре буенча башкарыла. Үзгәреш турында карарлар Арча муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан кабул ителә.

«Арча муниципаль районы Башкарма комитетының "Мәгариф идарәсе» МУ программасы буенча еллык отчет Арча муниципаль районы Башкарма комитетына хисап чорыннан соң 01 мартка кадәр җибәрелә.

**5.Программаның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеген бәяләү**

Арча муниципаль районында мәгариф өлкәсе торышын фаразлау мәктәп яшендәге балалар саны турындагы демографик фаразларга, икътисад, хезмәт базары, технологияләр үсеше фаразларына, Программада каралган чараларны гамәлгә ашыруның планлаштырылган нәтиҗәләренә нигезләнә.

Балаларга мәктәпкәчә, гомуми һәм өстәмә белем бирүне үстерүгә билгеле бер йогынтыны тышкы тенденцияләр ясый.

Беренчедән, мәктәпкәчә яштәге балалар санының чагыштырмача тотрыклылы булуы нәтиҗәсендә мәктәп яшендәге балалар саны үсәчәк. Икенчедән, күчеп урнашу структурасы үзгәрүен дәвам итәчәк: аз кешеле торак пунктларда яшәүчеләр саны кимиячәк һәм шәһәр халкы арта барачак.

**2021 - 2023 елларга Арча муниципаль районындагы мәгариф үсешенең программасының социаль нәтиҗәсе түбәндәгеләрдән гыйбарәт:**

-һәркем файдалана алырлык сыйфатлы белем бирү, район халкының төрле белем ихтыяҗын гамәлгә ашыру;

- инновацион тәҗрибәне үстерергә, сакларга һәм таратырга мөмкинлек бирә торган төрле мәгариф инновацияләрен аякка бастыру һәм аларга ярдәм итү өчен шартлар тудыру;

-педагогик кадрларны алдынгы педагогик тәҗрибәләр нигезендә әзерләү һәм яңадан укыту;

-җәмәгатьчелекне мәгарифкә социаль заказ формалаштыруга һәм гамәлгә ашыруга җәлеп итү;

-муниципаль мәгариф системасы учреждениеләренең конкуренциягә сәләтлелеген күтәрү;

-мәгариф системасының ресурслар ягыннан тәэмин ителеше үсеше, аның инвестицияләр җәлеп итүчәнлеге арту.

**Программаның нәтиҗәлелеген бәяләү таблицада күрсәтелгән индикатив күрсәткечләр нигезендә гамәлгә ашырыла:**

| № | Программа юнәлешләре буенча максатчан күрсәткечләр | 2021 | 2022 | 2023 |
|---|---|---|---|---|
| **1. Системаны үстерү һәм белем бирүнең нәтиҗәлелеген арттыру** | | | | |
| 1.1. | Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның гомуми саныннан мәктәпкәчә белем белән колачланган балалар өлеше, % | 70 | 78 | 82 |
| 1.2. | Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә йөрмәүче балаларга мәктәп алды әзерлеге белән колачлау, % | 100 | 100 | 100 |
| 1.3. | 3 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге балаларның гомуми саныннан мәктәпкәчә хезмәт күрсәтү һәм (яисә) аларны төрле оештыру-хокукый рәвештәге һәм милек рәвешендәге оешмаларда тәрбияләнүче 3 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге балалар өлеше, % | 100 | 100 | 100 |
| 1.4. | Мәктәпкәчә яшьтәге татар балаларының гомуми саныннан туган телдә тәрбияләнүче мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалар өлеше, % | 90 | 90 | 90 |
| 1.5. | Педагогларның гомуми саныннан мәктәпкәчә белем бирүне оештыруга федераль дәүләт таләпләрен кертү проблемасы буенча белем алган педагоглар өлеше, % | 100 | 100 | 100 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1.6. | ДОУ педагогларының гомуми санынннан һөнәри эшчәнлектә заманча белем бирү технологияләрен (шул исәптән мәгълүмати-коммуникация технологияләрен) нәтиҗәле кулланучы педагоглар өлеше, % | 80 | 82 | 84 |
| 1.7. | Беренче һәм югары квалификация категориясе булган педагоглар өлеше, педагогларның гомуми санында, % | 80 | 80 | 81 |
| 1.8. | Бер бала тарафыннан елына авыру сәбәпле калдырылган көннәр саны. | 3 | 3 | 3 |
| 1.9. | ДОУ балаларының гомуми санынннан авырмаган балалар өлеше,% | 40 | 43 | 45 |
| 1.10. | Сораштырылучылар саныннан мәктәпкәчә белем бирүнең сыйфатыннан канәгать булган халык өлеше, % | 98 | 98 | 98 |
| 1.11. | 1-6 яшьлек балаларның гомуми саныннан муниципаль мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләренә билгеләү өчен исәптә торучы 1-6 яшьлек балалар өлеше, % | 30 | 27 | 26 |
| **2. Икътисадны инновацион үстерү бурычларын хәл итүгә юнәлдерелгән заманча мәгариф моделен төзү һәм күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын бәяләү системасын үстерү** | | | | |
| 2.1. | Муниципаль мәгариф учреждениеләренең гомуми саныннан югары дәрәҗәдәге гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф учреждениеләре өлеше, % | 8,5 | 16 | 16 |
| 2.2. | Мәктәпләрнең гомуми саныннан төп гомуми белем бирү стандартына күчүне гамәлгә ашырган гомуми белем бирү учреждениеләре өлеше (гомуми саннан),% | 100 | 100 | 100 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 2.3. | Мәгарифнең федераль дәүләт стандартлары кертелүне исәпкә алып, квалификация күтәрелгән гомуми белем бирү учреждениеләре педагоглары өлеше (гомуми саннан), %; | 100 | 100 | 100 |
| | | | | |
| 2.4. | Программа дәрәҗәсе, үсеш дәрәҗәсе компетентлы алымны исәпкә алып эшләнгән гомуми белем бирү учреждениеләре өлеше, % | 100 | 100 | 100 |
| 2.5. | Ата-аналарга белем бирү һәм психологик белемнең төрле формаларына кертелгән, шулай ук гомуми белем мәсьәләләре буенча конференцияләрдә, форумнарда катнашучы ата-аналар өлеше, % | 80 | 85 | 87 |
| 2.6. | Бердәм дәүләт имтиханында катнашкан гомуми белем бирү учреждениеләрен тәмамлаучылар санынан бердәм дәүләт имтиханын тапшырган затлар өлеше, % | 100 | 100 | 100 |
| 2.7. | Уртача гомуми белем турында аттестат алмаган муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләрен тәмамлаучылар саны. | 0 | 0 | 0 |
| **3. Мәгариф белән идарә итү системасының нәтиҗәлелеген үстерү** | | | | |
| 3.1. | «Дәүләт һәм муниципаль идарә», «Менеджмент», «Персонал белән идарә итү» программалары буенча яңадан әзерлек үткән мәгариф учреждениеләре җитәкчеләре өлеше, % | 100 | 100 | 100 |
| 3.2. | Белем бирү һәм финанс-хуҗалык эшчәнлеге турында бастырып чыгарылган (массакүләм мәгълүмат чараларында, Интернет челтәрендә) гавами хисап булган мәгариф учреждениеләре өлеше, % | 100 | 100 | 100 |
| 3.3. | Интернет челтәрендә даими яңартыла торган сайтлары булган гомуми белем бирү учреждениеләре өлеше, % | 100 | 100 | 100 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 3.4. | Мәгариф учреждениесе белән идарә итүдә мәгълүмат технологияләрен кулланучы җитәкчеләр өлеше, % | 100 | 100 | 100 |
| 3.5. | Контракт биремнәре буенча эшләү системасына күчерелгән җитәкчеләр өлеше, % | 100 | 100 | 100 |
| **4. Педагогларның һәм мәгариф оешмаларының эш сыйфатын бәяләүнең яңа системасын булдыру** | | | | |
| 4.1. | Белем бирү хезмәтләренең сыйфатын канәгатьләндерү буенча ата-аналардан сорашытырулар үткәрү (елга сораштырулар саны) | 8 | 10 | 12 |
| 4.2. | Халыкның гомуми белем сыйфатыннан канәгать булуы (сораштырылучылар санынннан %) | 90 | 95 | 96 |
| 4.3. | Бәйсез экспертлар җәлеп ителгән район чаралары саны, берәмлек. | 35 | 37 | 37 |
| 4.4. | Рейтинглы белем бирү оешмалары системасы булу (әйе, юк) | әйе | юк | юк |
| 4.5. | Белем бирү сыйфатын бәяләүнең мәктәп эче системалары булган мәктәпләр өлеше, % | 100 | 100 | 100 |
| 4.6. | Профильле укыту программаларын гамәлгә ашыручы мәктәпләр өлеше, % | 100 | 100 | 100 |
| 4.7. | Югары сыйныфлар укучыларын профильле белем белән тәэмин итү, % | 100 | 100 | 100 |
| 4.8. | 9 класс укучыларын профиль алды белеме белән колачлау, % | 100 | 100 | 100 |
| 4.9. | Профессиональ өстенлекләр мониторингы белән бәйле 9-10 сыйныф укучылары өлеше, % | 95 | 100 | 100 |
| 4.10. | Белем бирү процессын гамәлгә ашыру шартларына заманча таләпләргә җавап бирә торган мәгариф учреждениеләре өлеше, % | 90 | 96 | 96 |
| 4.11. | Мәгариф оешмаларының яңа уку елына әзерлеге, % | 100 | 100 | 100 |
| **5. Мәгариф системасының кадрлар потенциалын үстерү** | | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 5.1. | Муниципаль мәгариф учреждениеләре педагогик хезмәткәрләр штатларының тупланышы | | | |
| | , % | 100 | 100 | 100 |
| 5.2. | Беренче һәм югары категорияле педагогик хезмәткәрләр өлеше, % | 80 | 85 | 86 |
| 5.3. | Укытучыларның гомуми санының педагогик эш стажы 5 елга кадәр булган гомуми белем бирү учреждениеләре укытучылары өлеше, % | 5,5 | 5,7 | 5,7 |
| 5.4. | Региональ һәм федераль дәрәҗәдәге педагогик осталык конкурсларында инновацион эшчәнлек өчен бүләкләр алуга катнашучы педагогик хезмәткәрләр өлеше, % | 20 | 23 | 23 |
| 5.5. | Мәгариф учреждениеләренең педагог хезмәткәрләренең гомуми санынннан мәгариф учреждениеләренең квалификацияләрен күтәргән, кабат әзерлек үткән педагогик хезмәткәрләре өлеше (5 елга 1 тапкыр исәпләгәндә), % | 4,5 | 5 | 5 |
| **6. Заманча белем бирү стандартларын һәм технологияләрен кертү** | | | | |
| 6.1. | Муниципаль мәгариф учреждениеләренең гомуми санынннан инновацион белем бирү программаларын, укыту технологияләрен, ысулларын һәм формаларын гамәлгә кертүче мәгариф учреждениеләре өлеше, % | 80 | 92 | 92 |
| 6.2. | Уку җиһазлары һәм техник чаралар белән тәэмин итү өлешендә ФГОС таләпләренә туры килә торган мәктәпләрнең предмет кабинетлары өлеше, % | 80 | 82 | 82 |
| **7. Милли мәгарифне үстерү** | | | | |
| 7.1. | Укучыларны татар теленә өйрәтү (туган тел яки дәүләт теле буларак)%, | 100 | 100 | 100 |
| 7.2. | Татар балаларын туган телдә укыту белән колачлау, % | 78,2 | 78,4 | 78,6 |
| 7.3. | Татар балаларын туган телдә тәрбияләү, % | 80,2 | 80,5 | 80,6 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 7.4. | Этно- мәдәни рус компоненты булган сыйныфлар (мәктәпләр) саны, берәмлек (мәктәп/класс) | 1/6 | 1/5 | 1/5 |
| 7.5. | Татар телендә шәһәр һәм республика чараларында (конкурслар, конференцияләр, фестивальләр олимпиадаларында) катнашучы балалар өлеше, % | 52,0 | 52,7 | 52,9 |
| | **8. Белем бирү киңлеген үстерү** | | | |
| 8.1. | Гомуми белем бирү мәктәбендә бер укучының компьютерга керү сәгатьләре белән тәэмин ителеш, % | 23 | 23 | 23 |
| 8.2. | Челтәр берләшмәләре эшендә катнашучы педагоглар өлеше, % | 72 | 87 | 89 |
| 8.3. | Мәктәп фәнни берләшмәләре әгъзалары булган укучылар өлеше, % | 6 | 15 | 17 |
| 8.4. | Укучыларның гомуми санынннан Бөтенроссия олимпиадасы, интеллектуаль конкурслар, фәнни-гамәли конференцияләр этаплары җиңүчеләре һәм призерлары өлеше, % | 5 | 8 | 8 |
| 8.5. | Чит телне тирәнтен өйрәнүче укучылар өлеше, % | 5,5 | 6 | 6,2 |
| 8.6. | Профильле лингвистик сменаларда катнашучы укучылар саны, кеше. | 100 | 100 | 100 |
| 8.7. | Интернет -форумнарда, конференцияләр, семинарларда катнашучы чит тел укытучылары өлеше % | 60 | 67 | 69 |
| 8.9. | Махсус белеме булган техник юнәлешле берләшмәләрдә эшләүче өстәмә белем бирү педагоглары өлеше, % | 60 | 65 | 65 |
| 8.10. | Балаларны өстәмә белем алу белән колачлау, шул исәптән: | 95,0 | 96,0 | 96,0 |
| 8.11. | техник һәм спорт-техник юнәлешле, % | 27 | 29 | 29 |
| 8.12. | физкультура-спорт юнәлеше, % | 15 | 16 | 18 |
| 8.13. | - туристик-туган якны өйрәнү юнәлешендә, % | 8 | 10 | 12 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 8.14. | - экологик-биологик юнәлешле, % | 10.5 | 10,5 | 10,5 |
| 8.15. | - сәнгать-иҗат юнәлеше, % | 37 | 42 | 44 |
| 8.16. | Башка юнәлешләр, % | 2,9 | 3,3 | 3,5 |
| 8.17. | Татар телендә өстәмә белем алган балалар өлеше, % | 68 | 70 | 72 |
| 8.18. | Арча районында яшәүче халыклар телләрендә өстәмә белем алган укучылар өлеше (башка милләт балаларының гомуми саныннан) | 0,4 | 0,4 | 0,5 |
| 8.19. | Татар телендә профиль сменалар белән колачланган балалар өлеше (мәктәп яны, җәйге стационар, палатка лагерьлары), | 25 | 26 | 28 |
| 8.20. | Тәрбияләүнең актуаль проблемалары буенча квалификация күтәрү курслары узган, шул исәптән балалар лидерлыгы проблемасы буенча да, тәрбия эше буенча директорлар урынбасарларының өлеше,% | 100 | 100 | 100 |
| 8.21. | Балалар һәм яшүсмерләр арасында асоциаль күренешләрне профилактикалау буенча яңа методикалар һәм технологияләр кертүче мәгариф учреждениеләре өлеше, % | 100 | 100 | 100 |
| 8.22. | Музей педагогикасын гамәлгә кертүче учреждениеләр өлеше, % | 55 | 61 | 61 |
| 8.23. | Балалар һәм яшүсмерләрне хокукый агарту эшен иң яхшы оештыруга район конкурсында катнашучы мәктәпләр өлеше (%) | 100 | 100 | 100 |
| 8.24. | Хокукый тәрбия мәсьәләләре буенча педагоглар өчен укыту семинарлары һәм тренинглары уздыруда катнашучы мәктәпләр өлеше ( %) | 60 | 70 | 70 |
